**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №181-32 «28» май 2024 ел

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карары белән расланган “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында”гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында"гы 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карарына яраклы рәвештә бюджет өлкәсе хезмәткәрләре, һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

**1.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган бюджет даирәсендә эшләүче аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2024 елның 1 июленнән күтәрергә.

2. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карары белән расланган

бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.4 пунктының беренче абзацында «12 688,00» санын «13 323,00» санына алмаштырырга;

2.2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2.3. бүлегенең 2.5 пунктындагы 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин